# “Бакырчы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе-балалар бакчасы” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесының эшчәнлеге турында киң җәмәгатьчелек өчен доклады

**2021 ел**

"Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесы район үзәгеннән 100 км ераклыкта, Акъегет авылы җирлегендә урнашкан.

Юридик адресы: 422535, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Бакырчы авылы, Советская урамы, 18 йорт.

Гомуми мәйданы 2900 кв.м. Җир участогы 0,60 га. Мәктәбебезне яфраклы агачлар, куаклар, чәчәк түтәлләре бизәп тора. Бакчада яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр үстерелә. 1 спорт һәм 1 уен мәйданчыгы бар.

Учреждение 1983 елда төзелгән һәм 1991 елда 1870 елны төзелгән бай йортын сүтеп бергә кушып эшләгән элеккеге төп белем мәктәбе бинасында урнашкан. Реконструкция нәтиҗәсендә мәктәпкә балалар бакчасы күчерелде.

Башлангыч мәктәптә 9 укучы белем ала. 1нче класста – 3 бала, 2 нче класста – 4 бала, 3 нче класста – 1 бала, 4 нче класста – 1 бала укый.

Балалар бакчасында 12 бала тәрбияләнә.

| Уку елы | 1 класс | 2 класс | 3 класс | 4 класс | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2015/2016 | 1 | 4 | 2 | 2 | 9 |
| 2016/2017 | 1 | 1 | 4 | 2 | 8 |
| 2017/2018 | 1 | 1 | 1 | 4 | 7 |
| 2019/2020 | 1 | 1 | 1 | 1 | 4 |
| 2020/2021 | 4 | 1 | 1 | 1 | 7 |
| 2021/2022 | 3 | 4 | 1 | 1 | 9 |

2020/2021 уку елында 7 бала укыды. Шуларның 4 се (1 нче сыйныф) аттестацияләнмәде. 3 укучының 1се – отличник булды. Өлгереш 100%, сыйфат 66,6 % тәшкил итте.

Укучы балаларыбыз түбәндәге конкурсларда катнаштылар:

-Всероссийский онлайн конкурс- “Садовые помощники”
Салахиева З.Ф., Шайхутдинова Ә.Г., Бикмуллина Э.А. 3 дәрәҗә диплом.
-Тукайга 135 ел тулу уңаеннан рәсемнәр конкурсы, Муса Җәлил шигырьләрен уку кокурсы
Барлык укучыларыбыз да катнашты.
-“Җәйгә Лайк” бәйгесе:
Бикмуллина Э.А диплом 3 баскыч
-Международный конкурс творческих работ “Здравствуй осень золотая”
Бикмуллина Ә.А. 1 урын, Салахиева З.Ф. 2 урын., Бикмуллин Ә.А., Зайнуллина З.З.,Шәйхетдинова Ә.Г. 3 урын (диплом)
-Всероссийский конкурс кулинарных рецептов «Бабушкины рецепты»:
Бикмуллина Ә.А., Зайнуллина З.З., Низамутдинова З.А., Салахиева З.Ф., Шайхетдинова Ә.Г. 3 урын (диплом)
-Международный онлайн-конкурс детских рисунков “Моя Родина-моя Республика”
Сәләхиева З.Ф. 3 урын (диплом)

Быел 2021/2022 уку елының 1 чиреген 7 бала 100% өлгергәнлек белән тәмамлады, сыйфат 66,6 %. 3 укучы аттестацияләнми.

Барлык укучылар да дәреслекләр белән тәэмин ителде.

Укучыларга югары белемле, 1 квалификацион категорияле 3 укытучы белем бирә.

Укучыларның гаиләләренең социаль статусы

| Тулы гаилә | Күп балалы гаилә 3 һәм аннан артык | Тулы булмаган гаилә | Авыр хәлле гаилә |
|---|---|---|---|
| 6 | 5 | 0 | 0 |

Балалар бакчасында катнаш төркемдә 14 бала тәрбияләнә.

Балаларның яшь буенча төркемнәргә бүленеше:

| Кечкенәләр 2-3 яшь | Уртанчылар 4-5 яшь | Зурлар 5-6 яшь | Мәктәпкә әзерлек 6-7 яшь |
|---|---|---|---|
| 5 | 1 | 4 | 4 |

Авыл җирлегендә 2 яшьтән 7 яшькә кадәр балаларның бакчага йөреше:

2017 ел – 100%

2018 ел – 100 %

2019 ел – 100%

2020 ел- 100%

2021 ел- 100%

Бакчага йөрүче балаларның гаиләләренең социаль статусы:

| Тулы гаилә | Тулы булмаган гаилә | Күп балалы гаилә (3 һәм аннан күбрәк) | Имин булмаган гаилә |
|---|---|---|---|
| 8 | 0 | 5 | 0 |

Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игътибар бирелә. Тәрбиячебез “Туганнан алып мәктәпкәчә” программасына нигезләнеп төзелгән балалар бакчасының үзенең төп гомуми белем бирү программасы буенча эшли. Бу программа үз алдына ***балаларны бар яклап та сәламәт шәхес итеп үстерү, аңа мәктәптә уку–тәрбия алу өчен кирәкле психологик процесслар булдыруны максат итеп куя***.

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр баланың үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклап үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Бакчада физкультура дәресе зурлар төркемендә өч тапкыр уздырылды - дәреснең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Дәресләрдә түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

- балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;
- балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;
- сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, житезлеген үстерү;
- сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;

Грипп, ОРЗ чорында группада сарымсак – суган инголяциясе ясалды. Фельдшер барлык эшчеләргә, балаларга грипптан прививка ясады. Эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында бакча

карантинга ябылмады, авыручы балалар саны да аз булды.Шулай ук COID-19 чире дә күзәтелмәде. Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында кардан тау ясалды. Кыш буе балалар рәхәтләнеп тау шудылар, шулай ук спорт мәйданчыгындагы шугалакта тимераякта шудылар.

Гомумән алганда, балаларның сәламәтлеген ныгыту өчен бездә барлык шартлар да үткәрелде. Елы буе “маска” режимы үтәлде, дезифекцияләр уздырылды, даими фильтр уздырылды. Мәктәпкә кертү, термометрия төгәл үтәлде.

Спорт мәйданчыгында төрле тренажерлар бар. Балалалар җәйге чорда футбол, волейбол уйнадылар, ә кышкы чорда хоккей уйныйлар, тимераякта шуалар, чана-чаңгыда шудылар.

Балаларны тукландыру да югары дәрәҗәдә оештырылган. Укучылар көнгә бер тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителә. Бер укучыны ашату өчен 51 сум 85 тиен акча бүлеп бирелә. Бакча балалары өч тапкыр ашыйлар. Меню сезонга карап төзелә, балалар ел буе яшелчә, җиләк-җимеш, натураль сок белән тәэмин ителә.

Ата-аналар балаларның өйдә туклануына да игътибар итсеннәр иде. Чипсы, кириешки, төрле экзотик җимешләрне үзебезнең бакчабызда үскән җиләк-җимеш, яшелчәләр белән алыштырсак балаларның сәламәтлеге өчен файдалырак булыр иде.

Балаларга хезмәт тәрбиясе бирү дә мәктәптә тиешенчә оештырылган. Укучылар катнашында мәктәп яны территориясендә язын һәм көзен өмәләр оештырыла. Бакчада яшелчәләр, чәчәкләр утырткanda да балалар теләп катнашалар. Шулай ук спорт мәйданчыгы, парктагы өмәләр дә укучылар катнашында уза.

Елның төрле фасылларында балалар белән табигатькә экскурсияләр оештырыла. Экскурсияләр нәтиҗәсендә балалар туган ягыбызның басу-кырлары, чишмәләре белән танышалар.

Безнең якларда үсүче агач-куаклар, бездә яшәүче кошлар турында белемнәрен киңәйтәләр. Табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәнәләр. Туган ягыбыз белән горурлану хисләре тәрбияләнә.

"Бакырчы башлангыч мәктәп-балалар бакчасы" белән элемтәдә торалар:

Бакырчы фельдшер-акушерлык пункты;

Норлат участок хастаханәсе;

Бакырчы авылы клуб-библиотека үзәкләштерелгән комплексы.

Бакырчы "Суфия" мәчете.

"Бакырчы башлангыч мәктәп-балалар бакчасы" бинасы төзек хәлдә. Кабинетлар гигиена таләпләренә туры килә һәм укыту процессы өчен рациональ оештырылган. Суүткәрү, канализация төзек хәлдә. Газ белән җылытыла.

Узган елда түбәндәге эшләр эшләнде:

1. Кабинетларда һәм балалар бакчасында косметик ремонт башкарылды.
2. Уз кочебез белән балалар бакчасы һәм ашхәнә түбәсе яңа калай белән ябылды. Бу эштә мэчет һәм авалның "Ак әбиләре" бик күп материаль ярдәм күрсәттеләр.
3. Укучылар өчен җылы туалет булдырылды. Программа буенча.
4. Мәктәп музейлары яңартылды һәм тулыландырылды.

"Бакырчы башлангыч мәктәп-балалар бакчасы" түбәндәге юнәлешләр буенча эшен дәвам итә:

- Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту; белем һәм тәрбия алу процессында балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- Гражданлык-патриотик үзаң, инициативалылык, мөстәкыйллек, толерантлык тәрбияләү;

- Сыйфатлы белем бирү.

Бүгенге көнгә безнең проблемалар:

1. Мәктәп ягы түбәсен яңартырга кирәк.
2. Балалар бакчасы мәйданчыгының чикләштерелү киртәсен яңадан тоту.

Мәктәп директоры: Җ.Т.Сафиуллин

13.12.2021 ел